ГЛАВА БАЙРЯКИ-ТАМАКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Байряки-Тамак, ул.Новая, д.37, ,
423964

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЙРӘКӘ-ТАМАК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Бәйрәкә-Тамак авылы, Яңа урамы,
37 йорт, 423964

Тел.:(85593) 5-13-25, факс:5-13-24, e-mail: Btam.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

N 4 29.11.2021

2022 елда Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегендәге
Подгорный торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү
һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы карарының 25.1, 56 санлы маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, 2019 елның 17 июлендә 8 санлы карары белән кабул ителгән Ютазы муниципаль районы «Бәйрәкәтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14, 81 маддәләре, 2019 елның 10 сентябрендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советының 11 санлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында»гы нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Бәйрәкәтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елның 11 декабрендә 13.00 сәгатьтә Күпфункцияле үзәк бинасы янында,Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Подгорный бистәсе, Үзәк урам, 22А йорт адресы буенча 2022 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Подгорный торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«2022 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Подгорный торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булмаган һәр кешедән,көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган тормыш иптәшләре, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

-су белән тәэмин итү линиясен реконструкцияләү (материаллар, җиһазлар сатып алу, эшләр өчен килешү буенча түләү);

-Подгорный бистәсенә керә торган юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (асфаль сатып алу, кайтару, түшәү, эшләр өчен килешү буенча түләү);

-Подгорный торак пунктында корыган агачларны кисү, территорияне чүп-чардан чистарту (килешү нигезендә эшләр өчен түләү);

- авыл эчендәге юлларны карап тоту (грейдер белән узу, кардан чистарту, килешү буенча түләү).

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Бәйрәкәтамак авыл җирлегендәге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында (http://jutaza.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында кабул ителгән көннән 5 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көннән (халыкка җиткерелгән көннән) үз көченә керә.

Ютазы муниципаль районы
Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башлыгы Ф.В.Әхмәтов